СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

18.07.2019 Алабуга № 383

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлекләре милкендәге күчемсез мөлкәт объектлары турында мәгълүматны бастырып чыгару тәртибен раслау хакында

2003 елның 6 октябрендә чыккан 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга таянып, 2018 елның 5 апрелендә (2018 елның 15 маендагы Пр-817ГС номерлы) Россия Федерациясе Дәүләт Советы утырышы йомгаклары буенча Россия Федерациясе Президенты йөкләмәләре исемлеген гамәлгә ашыру максатларында, муниципаль милектә булган объектлар турында мәгълүматны бастырып чыгаруны һәм актуальләштерүне тәэмин итү өлешендә Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАРАР кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлекләре милкендәге күчемсез мөлкәт объектлары турында мәгълүматны бастырып чыгару тәртибен расларга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җир-милек мөнәсәбәтләре һәм табигатьтән файдалану мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Рәис Г.Е.Емельянов